• ЧАРАЛАР

# Атнабай әсәрен якташларына бүләк итеп

15 ноябрь көнне без, Борайның "Заман" халык театр-студиясе үзешчәннәре, театрыбыз режиссеры Радис Солтанов җитәкчелегендә, ике район арасындагы яшәп килгән аралашу традициясен дәвам итеп, күрше Тәтешле районына юлландык. Безнең максат бөек Атнабайның "Законлы никах белән" комедиясен якташларына бүләк итү иде.



Көнебез бик тыгыз үтте. Тәтешлеләрнең жылы чәennнән соң без иң беренче булып Ә.Атнабайга куелган һәйкәлгә юлландык. Тирән ихтирам хисе белән әдипнең аяк очына гөлләмәләребезне салдык. Якында гына булган туган якны өйрәнү музееn, Татарстанның халык артисты Хәния Фәрхигә багышланган музейны, аңа куелган һәйкәлне күзләдек. Алар белән дә таныша алмавыбызга күңел кырылса да, вакыт тыгын булу сәбәпле, район мәдәният йортына ашыктык.

Без чыгышыбызның башында халык шагыйренең тормыш юлына, иҗатына байкау ясадык. Аннан инде спектакль башланып китте. Чыгышыбыз бик уңышлы булды. Атнабайның туган җирендә шушы әсәрне сәхнәләштерү – иҗатына, тормыш юлына зур ихтирамыбызны күрсәтү ул. Күп не янә тәмле-тәмле ашлар көтә иде. Тәтешлеләр бик кунакчыл халык. Уңыш үзе дә елмая иде, ахыры, безгә. Музейлармузей. Әлбәттә, икесен дә күрергә ашыктык без. Беренче булып туган якны өйрәнү музеена кердек. Аны карагач, үз альбомнары, үз кулы белән язганнары белән танышырга ашыктык. Без монда да үзебезгә күп ачышлар ясадык. Ике музей итеп, жылы сүзләр белән озатып калучы тәтешлеләргә һәм сәяхәтебезне оештырган район хакимияте башлыгы Ру-

ланып китте. Чыгышыбыз бик уңышлы булды. Атнабайның туган җирендә шушы әсәрне сәхнәләштерү – иҗатына, тормыш юлына зур ихтирамыбызны күрсәтү ул. Күп рәхмәтләр әйтеп, шатланып калды кичәбездән тәтешлелеләр. Һәрберсе безгә күңелендә туган тәэссоратлары белән бүлешергә, җылы сүзләрен җиткерергә теләде. Шулкадәр игътибарлы, ихтирамлы тамашачы үзе дә безне таң калдырды.

Чыгышыбыздан соң безне янә тәмле-тәмле ашлар көтә иде. Тәтешлелеләр бик кунакчыл халык. Уңыш үзе дә елмая иде, ахыры, безгә. Музейларны күреп җитешмәгәнебезне ишеткәч тә алар бу хатаны төзәтергә тәкъдим иттеләр. Кара төн булуына карамастан, без музейлар карарга киттек. Без баруга ишек төбендә экскурсовод елмаеп көтеп тора иде инде.

Бер район үзәгендә ике музей. Әлбәттә, икесен дә күрергә ашыктык без. Беренче булып туган якны өйрәнү музеена кердек. Аны карагач, үз тарихларын белә, өйрәнә, саклый, дигән фикердә калдык без тәтешлелеләр турында. Экскурсоводның туган ягы, якташлары турында шулай яратып сөйләве таң калдырды. Аннары барыбыз да яратып тыңлаган Хәния Фәрхинең шәхси әйберләре: концерт киемнәре, альбомнары, үз кулы белән язганнары белән танышырга ашыктык. Без монда да үзебезгә күп ачышлар ясадык. Ике музей да бик бай, тирән эчтәлекле, заманча җиһазландырылган.

Салынган һәйкәлләр, ачылган музейлар – барысы да тәтешлелеләрнең үз туган якларын, үз якларының бөек кешеләрен яратуы, санлаулары турында әйтеп тора.

Безне шулай яхшы кабул итеп, җылы сүзләр белән озатып калучы тәтешлелеләргә һәм сәяхәтебезне оештырган район хакимияте башлыгы Рушан Гәрәевка, мәдәният һәм яшьләр сәясәте идарәлеге начальнигы Илгиз Харисовка, район мәдәният йорты директоры Илшат Әхмәтовка олы рәхмәтләребезне белдерәбез.

**Ләйсән МУЛЛАГАЛИЕВА,**
**Борай икенче гимназиясенең башкорт теле укытучысы.**

# “Кайтам әле туган авылыма…”



Шушы көннәрдә Яңа Тазлар авылында үзенең матур шигырьләре белән халык арасында танылу алган Илдар Нуртдиновның иҗат кичәсе булды. Бу искиткеч, эчтәлекле чараны Иске Тазлар авылы китапханәчесе Лида Әюпова һәм шушы системада берничә дистә ел эшләп лаеклы ялга чыккан Әнибә Шафыйкова оештырды. Шигърият кичәсе “Кайтам әле туган авылыма, кайтам әле тагын яшьләккә” дип аталды. Кичә барышында Илдарның тормыш юлы, шигъриятккә ясаган беренче адымнары турында сөйләнелде.

Илдар Заһит улы үзе тумышы белән Иске Тазлар авылыннан. Шигырьгә мәхәббәте аның кече яшьтән үк була. Ул шуларны акрынлап ак кәгазь битләренә төшерә бара. Менә, ниһаять, аларның саны бихисапка әйләнә.

Күңелләрдә уелып калырлык кичәгә Яңавылдан да кунаклар – “Замандаш” әдәби түгәрәге кураторы, үзәк китапханәнең китап белән тәэмин итү бүлеге җитәкчесе Дания Хәкимова, БРның атказанган мәдәният хезмәткәре, Гали Чокрый премиясе лауреаты, “Замандаш” әдәби түгәрәге әгъзасы Җәүдәт Хәкимов килгән иде. Шагыйрьнең китаплары, архив материаллары белән баетылган “Йөрәгемдә сүнмәс ялкын бар”, дип аталган китап күргәзмәсе дә күпләрне үзенә җәлеп итте.

Кичәне Дания Хәкимова белән Әнибә Шафыйкова оста итеп алып барды. Илдар Нуртдиновның шигырьләренә язылган җырларны Зенфира Фәрхетдинова башкарды. Дания Хәкимова башкаруында шигырьгә көй язучысы Җәүдәт Хәкимов музыкаль яктан бизәде.

Илдарның беренче укытучысы Фәйрүзә Нигъмәтҗанова үзенең истәлекләре белән уртаклашты, татар теленнән белем биргән укытучысы Рәүфәнә Хәбибуллина чыгыш ясады.

Бәйрәмдә Илдарның туганнары, авылдашлары үз истәлекләре белән уртаклашты. Аларның шигырьләрендә туган авылга, балачакка, әнкәйләргә, мәхәббәткә мәдхия сүзләре яңгырады. Үзенең чыгышында Илдар киләчәккә планнары белән уртаклашты, шигырьләрен укып ишеттерде, туган мәктәбенә үзенең бүләген тапшырды.

Кичәдә Яңа Тазлар авыл биләмәсе башлыгы Илүс Даутов, мәктәп укытучысы Лүзә Дугинова һәм башка чыгыш ясаучылар Илдарга киләчәктә тормышында һәм шигърияттә иҗади уңышлар, яңадан-яңа шигырьләр, җырлар иҗат итүен теләделәр.

Бәйрәм кичәсе бер тында узды. Илдарның киләчәктә яңадан-яңа шигырьләре язылып, табадан гына төшкән китап бәйрәменә тагын да җыелырбыз дигән өметтә калабыз, дип таралышты кунаклар.

**Гөлназ ХУҖИНА.**
**Әнибә ШАФЫЙКОВА фотосы.**